Мөдәррис Әгъләмов

Без, без, без идек

Мөдәррис Әгъләмов

Без, без, без идек



КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1980

С(Тат)2
Ә20

Художнигы *Айдар Үтәгәнов*

$\frac{70701-228}{М\ 132(03)-80}$ 176—80 С (Тат)2

© Татарстан китап нәшрияты, 1980.

Безнең матур дөньябыз

Без

Безме?
Без бик күп, малай!
Бик күп тә түгел алай:
Кешегә кирәк кадәрле
Йортлар төзәрлек кенә,
Китаплар яза алырлык,
Сүзләр тезәрлек кенә.

Без күп тә түгел алай,
Ә чынлыкта күп, малай:
Дөньяда ачлык булмаслык
Иген игәрлек санда,
Һәм ялангачлык булмаслык
Кием тегәрлек санда.

Безме?
Без бик күп, малай!
Бик күп тә түгел алай:
Сабантуй мәйданнарында
Көрәш башларлык кына.
Шул көрәштә яманлыкны
Егып ташларлык кына.

Без күп тә түгел алай,
Ә чынлыкта күп, малай:
Кешелекне һәлакәттән
Алып калырлык санда,
Исән-имин киләчәккә
Алып барырлык санда.

Безме?
Без бик күп, малай!

Бик күп тә түгел алай:
Бабайлар көткән дөньяны
Күтәрлек кадәр генә,
Алар хыялланган илгә
Җитәрлек кадәр генә.

Безнең авыл

Әйбәт түгел мактану,
Кайчагында чак калам.
Ә бу юлы чын-чынлап
Мактанмыйча мактанам.

Безнең авыл Ватанга
Биргән әллә кемнәрне:
Һәммәсе дә танылган,
Һәммәсе дә һөнәрле.

Алар иген игәләр,
Төзелештә эшлиләр,
Эшчеләр бит шәһәргә
Күктән генә төшмиләр.

Алар безнең авылда
Мәктәп юлын таптаган,
Алар белән мин бүген
Аяк терәп мактанам.

— Нәрсәсе бар ул кадәр
Бик мактанырлык? — диләр.
— Һәммәсе бар, тик сездә
Космонавт юк бит,— диләр.

Ә мин әйтәм: ул кадәр
Ашыкмагыз, дусларым,
Без үсәбез,
Сез әле
Онытмагыз без барын.

Без хәзер зур көч булдык

Икәү идек, өч булдык.
Без хәзер зур көч булдык:
Үзем, энем, сеңелем бар,
Сеңелем ята бишектә.
Айгөл, диеп эшдәшсәк
Елый башлый: ишетә.

Менә мин йөреп киләм,
Төрлесен күреп киләм,
Һәммәсен сөйләп бирәм,
Тыңларга теләмәсә,
«Бәлли-бәү» көйләп бирәм.

Кайчагында кыза ул,
Тузыныпмы туза ул.
Ә-ә-ә, шулаймы син, димен,
Усал абзаң мин, димен.
Шундый каты кычкырам,
Туктап кала аптырап:
«Ай» да юк дим, «гөл» дә юк,
Айгөлме — син? — Айелак.

Аннары уйлап куям,
Мин арада өлкәне.
Минем өлкән икәнне
Айгөл белми бит әле.

Минем кадәр зур булып
Үсеп җитәр берчакны.
Иптәшләре сорарлар:
— Сиңа диеп кем такты
Бу яман кушаматны?

Ә бит аның елавы —
Шулай мәми соравы.
Белми әле дөньяны,
Сөт эчә дә сөт эчә.
Кеп-кечкенә, ә белә:
Кызык түгел үсмичә.

Бәйрәм бүген бездә

Кояш баеп килә...
Үрелә-үрелә карый,
Керә алмый өйгә.
Ул көнләшеп карый
Батып барган көйгә.

Мин шатланып йөрим,
Канатланып йөрим,
Әти тирәсендә,
Әни тирәсендә
Гел таптанып йөрим.

Күкрәгемә сымый
Шатлыкларым минем,
Бер ягымда сеңелем,
Бер ягымда энем.

Кояш баеп килә,
Шундый рәхәт өйдә,
Чөнки бүген бәйрәм,
Олы бәйрәм бездә.

Бәйрәм: бүген безнең
Өйдә һәммәбез дә...

Саубуллашу

Иске мәктәп калды безнең
Моңсуланып, боегып,
Карт чаганнар ботагының
Арасына сыенып.

Ә башкалар безнең шушы
Мәктәпне дә белсеннәр,
Кайда укырга өйрәндек —
Килсеннәр дә күрсеннәр.

...Ал кояш көнбагыш иде,
Ай тәти якты иде;
Йолдызлар учактан очкан
Чаткылар чаклы иде.

Уен гына иде безгә
Җиту җирнең читенә...
Утырасың тауга менеп
Аякны селкеп кенә.

Беренче битләрен ачып,
Башламый торып «А»ны,
Барсын белеп кара әле,
Өйрәнми Әлифбаны.

Ормыйча да, сукмыйча да,
Колакны борып шәпләп...
«А»дан «Я»га кадәр серне
Ачты безгә ул мәктәп.

Өлкәннәр эшне бетереп
Ишекләрне ачуга,
Иске мәктәпне калдырып
Килдек без яңасына.

Элеккесе карап калды,
Теләп калды яхшылык,
Карт чаганнар ботагының
Арасыннан яктырып.

Безнең «диңгез»

Диңгезгә кергән дә юк,
Диңгезне күргән дә юк.
Үсик тә бераз гына,
Күрмичә булмас барып.

Аны бик ярсу, диләр,
Иртә-кич алсу, диләр.
Ә суы тозлы, диләр,
Шулмы су булды, юләр!

Ничә көн яңгыр ява,
Безнең ис китми аңа.
Ява тора, менә без
Чабып барып керәбез.

Ай үсәсен көн үсеп,
Үсәбез дә үсәбез.
Яңгыр җепләре буйлап
Күккә менеп төшәбез.

Зур булып, эреләнеп
Агып ята гөрләвек.

Әйттек аңа: «Очынма!»
Кәсләр салып шушында,
Елгага төшмәс борын
Туктаттык бүлеп юлын.
Урам чатлары тулып
Җәелде «диңгез» булып.

Диңгезне күргән дә юк,
Анда су кергән дә юк;
Кирәкми дә ул безгә,
Без хәзергә «диңгездә».

Канаудан ташып чыккан,
Ишелеп төшкән болыттан,
Ур-ра! Диңгез ясадык,
Безнең диңгез тубыктан.

Бу урамнар тар әле ул,
Киләчәктә бар әле ул
Чын диңгезне күрәселәр,
Колач җәеп йөзәселәр.

Безнең язу

Безнең бабайлар Ватанга
Куркыныч килгән чакта
Язып киткәннәр ишеккә:
«Һәммәбез дә фронтта!»

Без, аларның оныклары,
Онытмыйбыз бу хакта,
Кирәк булса, калыр язу:
«Һәммәбез дә фронтта!»

Басуга чыгып киткәндә
Ишекнең иң түрендә
Безнең элгән язу калды:
«Һәммәбез чөгендердә!»

Урамыбыз тузаны

Бу инде безнең урам,
Урам башында торам.
Бабам илне сакларга
Кузгалган менә моннан.

Мин бабамны күрмәдем,
Беләм утка кергәнен.
Нәкъ минем йөрүем, диләр,
Аның атлап йөргәнен.

Менә бу безнең урам.
Уртасында ук торам.
Әтием урман, болынга
Ияртә мине моннан.

Карап йөрдек урманын,
Айкап болын, кырларын.
Шул кадәрле рәхәт ул
Иркендә булуларың.

Тик сагындырды урам,
Урам башында торам.
Урман матур,
Болын матур,
Тик аларда юк тузан!

Тузан сагынган мине,
Килеп йөзгә бәрелде.
Китеп торсаң, урамыңның
Тузаны да кадерле.

Клубта

Кызыклар тыңлар өчен
Клубка килдек кичен...

— Әгәр йокламасагыз,
Бик тавышланмасагыз,
Өлкәннәргә тыңларга
Комачауламасагыз,
Утырыгыз, — диделәр.
Түрдән урын бирделәр.

Анда концерт булганга,
Утырдык без иң алда...
Апалар да җырлады,
Абыйлар да җырлады.
Без кул чаптык,
Ә алар
  Ялындырып тормады.

Ә аннары...
Ә аннары
Бик озак булды әле,
Колак төбендә ул җырлар
Яңгырап торды әле.

Абый кызык сөйләде,
«Ник кердегез»? — димәде,
«Минем нәни дусларым
Биредә күбәү»,— диде.
Бишек җыры җырлады:
— Әлли-бәлли-бәү... — диде.

Шаярып, көлеп кенә
Җырлап йоклаткан мине.
Уйлап ятам:
Ә өйгә
Кем алып кайткан мине?

Җир-ана, кояш һәм кешеләр

(баллада)

Халкымда мәзәкләр,
Әкиятләр никадәр...
Тик һаман: Бернәрсә
Сөйләче, дисәләр,
Тынгылык бирмичә,
Уяна уемда,
Уяна уемда
Өр-яңа легенда.
Уйлап та тапмадым,
Беркем дә бирмәде,
Кояш,
жир,
табигать
Матурлап сөйләде.

* *
*

Җир әле ул чакта
Яшь, чибәр булган, ди,
Кояшка карап гел
Елмаеп торган, ди.
Ә Кояш бик салкын,
Боз тавы шикелле,
Боз тавы шикелле,
Шулай да сөйкемле.
Ул да Җир өстеннән
Алалмый күзләрен,
Ул дәвам итә гел
Яхшылык эзләвен.
Ә Җир гел, әйләнеп,
Кояшка табынган,
Һәм Кояш шул хистән
Ут булып кабынган.
Кабынган һәм җиргә
Тараткан нурларын,
Эретеп су иткән
Карларын, бозларын.

* *
*

Кояшның һәм җирнең
Мәхәббәт җимеше,
Тормышка омтылган
Яңа зат — ул Кеше.
Җир-ана аермый
Олыга, кечегә;
Улларын, кызларын
Кадерләп үстерә.
Берсен дә какмый ул,
Бертигез ярата,
Балалар тупырдап
Басалар аякка.
Кояш та аларны
Бертигез ярата,
Төн ясап йоклата,
Көн ясап уята.
Әнилек хисе дә,
Әтилек хисе дә
Нәкъ менә шулардан
Күчкәндер Кешегә.

* *
*

Җир ана кызганмый
Нефтьне, руданы.
Әйтә ул: «Матурлап
Бизәгез дөньяны!
Яшәгез хезмәттән
Ямь табып, тәм табып!»
Уллары шуннан соң,
Җиңнәрен сызганып,
Эшли дә башлыйлар,
Ә эшләр берничә.
Һәр эштә шатлыклар,
Кайгылар төрлечә...
...Кайсысы, шатлыклар
Кичерә-кичерә,
Кырларда шаулатып
Игеннәр үстерә.

Кайсысы аларга
Әзерли машина,
Яналар, дөрлиләр
Хезмәттә барсы да.
Җир һаман яшәрә,
Җир һаман ямьләнә,
Кайсысы нур чәчеп
Атыла галәмгә.

Кайта ул нур өстәп,
Ямь өстәп дөньяга.
Колачын киң җәеп,
Каршылый Җир-ана.

* *
*

Җир-ана кызганмый
Нефтьне, уранны.
Әйтә ул: «Бизәгез
Матурлап дөньяны!»
Бер төсле булмый шул
Ананың уллары,
Берсе Җир-анадан
Ала да уранны,—
Кодрәтле зур көчнең
Таба өр-яңасын,
Тик аннан ясый ул
Атом-төш бомбасын.

Ә башка уллары
Хезмәттә яналар.
Эшләрен бүлмичә,
Атом да табалар.
Әйтәләр: «Куркыта
Алмассың көч белән.
Әйдә без көчләрне
Сынашыйк эш белән.
Атом — ул әзер көч,
Ятмасын гел бушка,
Сугышка түгел, ә
Җигелсен тормышка!»

Бу булмый коры сүз,
Күп үтми, чыннан да,
Атомнан көч алып,
Бозваткыч боз яра,
Атомнан көч алып,
Зур ГЭСлар кабына.
Кешелек һәрвакыт
Тынычлык ягында.

* *
*

Изге Җир-ананың
Хезмәтчел уллары
Матурлап,
яшәртеп
Бизиләр дөньяны.
Кайсысы, шатлыклар
Кичерә-кичерә,
Кырларда шаулатып
Игеннәр үстерә;
Кайсысы балкыта
Өр-яңа калалар,
Күк йөзе шикелле
Нур чәчеп яналар.
Шул нурлар эчендә
Ишетелә җыр гына...
Ә җыр гел туганлык
Һәм шатлык,
Һәм бәхет,
Һәм дуслык турында.

Халкымда мәзәкләр,
Әкиятләр никадәр,
Тик һаман: Бернәрсә
Сөйләче, дисәләр,
Тынгылык бирмичә
Яңара уемда
Нәкъ менә мин сезгә
Сөйләгән легенда.

Матурлык безнең белән

2 У-244

Матурлык минем белән

Зур, матур, биек йортлар,
Тәрәзәләрдә утлар...
Ишектән килеп керәм.
Кайда гына барсам да,
Матурлык минем белән.

Алда күл, янда болын...
Уйнаклап йөри колын...
Мин дә тәгәрим, көләм,
Чөнки кайда булсам да,
Матурлык минем белән.

Сикереп төшәм суларга,
Шундый рәхәт суларга!
Тауларга күтәреләм.
Кайда гына булсам да,
Матурлык минем белән.

Җирем иркен, илем киң,
Горур йөрергә мөмкин,
Имичә башны түбән...
Чөнки кайда булсам да,
Матурлык минем белән.

Күзем — җанлы табигатем

Күзем — җанлы табигатем,
Күзем — канатлы кошым!
Камыллы кырлар өстеннән
Мин синең белән очыйм.

Суларың җанлы, йөгерә...
Тәннәре тимгел-тимгел...
Син аңа канатың белән
Кагылып киткәнсеңдер.

Мәктәбем бакчаларына
Җәелә синең төсең,
Син яфрак булып бүлмәгә
Тәрәзәдән керәсең.

Кунасың партам өстенә,
Китабым битләренә.
Син кояш булып уйныйсың
Йөземдә көлә-көлә.

Яфракларыңны актарып
Серләр эзлисең һаман.
Ә минем җәен җыелган
Китабым укылмаган.

Яшел аланга сарыдан
Язып торасың һаман...
Минем дә ап-ак битләрем
Күп әле,
Язылмаган.

Чакырасың киңлекләргә,
Шаярасың, күрәсең.
Көзем, син алтын кошым,
Син алтын табигатем.

Яшәү

Бөреләр үрли кояшка,
Балалар йөгерә уйнап...
Күчә-күчә илдән илгә
Май килә дөнья буйлап.

Даһилар кебек гади ул,
Гадиләр кебек тыйнак.
Май килә дөнья буйлап.

Чәчәккә, гөлгә, яшелгә
Кумә дә дөньяларны,
Тыныч булсын, дигән сыман,
Дөньялар гына бары
Заманның башыннан сыйпап
Ил буйлап китә ары,
Яшәртеп дөньяларны.

Башкаен горур күтәреп,
Дөньяга бага кеше —
Күңлекне каплый яшеллек,
Яшеллек — яшәү төсе.
Яңа Май белән раслана
Ильичның үлмәс эше.
Яшеллек — яшәү төсе.

Яфрак җыры

Гомергә дә тиңлисез,
Сагышка да тиңлисез,
Мәңге шулай яшел булып
Калырга да димлисез.

Ә мин җир җылысы белән
Кояшка табан менәм.
Көз җитүгә саргаям да
Сикерәм тагын түбән.

Һәркемнең булсын минем күк
Сикереп төшәр җире.
Мин сезгә килер язларга
Калдырып китәм бөре.

Ул бөре сезне сагынып
Яз җиткәч йөгереп чыгар.
Таң калыр мине яңадан
Кайтмас дип юраучылар.

Йорт казлары

Канат җилпеп очмадылар,
Булды алар җәен тыйнак.
Хәзер әнә борчылдылар:
Кыйгак-кыйгак!
Күкләр тулы кошлар җыры,
Шул авазның барсын җыйнап
Канат җилпеп куйды алар:
Кыйгак-кыйгак!

Аяклары су өстендә,
Очты алар елга буйлап.
Китеп тынды авазлары:
Кыйгак-кыйгак!

Югалдылар, киттеләр, дип,
Бик борчылып йөрдем, уйлап.
Мине һаман сагындырды:
Кыйгак-кыйгак!

Тәпи-тәпи кайтты алар,
Гаепледәй, авыл буйлап.
Бер талпынып алу ярый:
Кыйгак-кыйгак!

Инешнең илгә кайтуы

— Кайда болай каударланып
Ашыгасың, инеш?
— Бер кайтырмын яңгыр булып
Сезгә исән килеш.

— Кайдан болай каударланып
Ашыгасың, болыт?
— Илләр гизеп кайтып киләм
Сезгә яңгыр булып.

— Кай иллэрдэн килүең бу,
Бэрэкэтле яңгыр?
— Миннэн сезгэ гүзэл илнең
Бэрэкэте калыр.

...Үзеннэн киткэн суларның
Үткэн юлын уйлап,
Туган җирнең саф сулары
Куйды авыр сулап.

Кечкенэ легенда

Борынгы Чулман аккан
Ярына тулып,
Ярсыган ул мэңгегэ
Буйсынмас булып.
Кеше эйткэн: «Мин сиңа
Кидертэм йөгэн,
Мин сине хезмэт итэргэ
Өйрэтэм!» — дигэн.
Чулман, ярыннан ташып,
Тэгэрэп көлгэн:
«Балык бирэм, су бирэм,
Шул җитэ»,— дигэн.
Кеше эйткэн: «Мин чынлап
Ике уйламам,
Телим икэн суыңнан
Утлар чыгарам!»
Чулман тагын да көчлерэк
Тэгэрэп көлгэн;
«Мин бит су, мин үзем утны
Сүндерэм, — дигэн.—
Ничэ гасырлар,— дигэн ул,—
Мин гомер итэм.
Ахрысы хэзер кешелэр
Бөтенлэй бүтэн!»

...Белергә теләсәң әгәр
Бәхәснең соңын,
Чаллыга, Чулман ярына
Илтәчәк юлың.
Кеше Кама елгасына
Кидертте йөгән.
Ишеттем, Чулман Кешегә
«Ышанам»! дигән.

Арча кыры

Чыпчыкларга кыек — оя,
Бөркетләргә — биек кыя.
Киңлекләргә сыймый бөркет,
Җырга сыя...

Арча кыры. Ершов урамы.
Ничә тапкыр үттем мин аны...
Атлап узган саен уйланып,
Үскән кебек булам бер башка,
Мулланурга баш игән сыман
Күңелдән баш иям Ершовка.
Утлы гомерендә кешенең
Моннан зур эш, бәлки, булмастыр...
Власть кадәр олы властьның
Берсен төшер,
Берсен урнаштыр...
Халык өчен яшә. Ирекне
Һәр адымда сакла, һәркайда —
Милләте юк аның — ирекнең,
Казан да бер аңа,
Байкал да...
Арча кыры. Ершов урамы.
Ничә тапкыр үттем мин аны.
Ут гомерләр калмый юк булып,
Ялкын булып дөрли уйлары...
Галимҗаннар җаны биредә,
Мулланурлар нуры — бу көлтә.

Мәңгелек ут булып килгәннәр
Воронежда туган егеткә.
Арча кыры. Ершов урамы.
Мәңгелек ут барлый дөньяны.

Билгесез солдат

Без киләбез сиңа буранлы кышларда,
Киләбез сиңа тынлыкны саклап.
Син безнең абый,
Син безнең әти,
Син безнең бабай, билгесез солдат.

Без киләбез сиңа яңгырлы көзләрдә,
Сары яфраклы сукмактан атлап.
Гөл булып үстең,
Җил булып истең,
Син безгә күчтең, билгесез солдат.

Үлгәннәр далада гөл булып үскәннәр,
Үлгәннәр далада җил булып искәннәр.
Җилләрне һәрвакыт тойганнар исәннәр.
Гөлләрне һәрвакыт җыйганнар исәннәр.

Без киләбез сиңа кояшлы җәйләрдә,
Бөек нәселнең дәвамын раслап...
Син безнең абый,
Син безнең әти,
Син безнең бабай, билгесез солдат.

Үлгәннәр далада гөл булып үскәннәр,
Үлгәннәр далада җил булып искәннәр.
Җилләрне һәрвакыт тойганнар исәннәр.
Гөлләрне һәрвакыт җыйганнар исәннәр.

Без киләбез сиңа чәчәкле язларда,
Синең хактагы яз җырын ятлап.
Җил булып истең,
Гөл булып үстең,
Син безгә күчтең, билгесез солдат.

Үлгәннәр далада җил булып искәннәр,
Үлгәннәр далада гөл булып үскәннәр.
Җилләрне һәрвакыт тойганнар исәннәр.
Гөлләрне һәрвакыт җыйганнар исәннәр.

Батырлыкның башы

Безнең көннәрдә Газинур батырлыгын кабатлаган Рифкать Миргазизов истәлегенә.

Колач җәям дисә,
Агып ята Чулман,
Моңы Рифкатьнең
Күкрәгенә тулган.
Язгы шомырт кебек
Ташкан күбекләнеп,
Кичке эңгерләрдә
Агып чыккан бәреп.

Аякларын юган
Таң чыгының яше.
Батырлыкның башы
Әнә шунда яши.
Нәни йөрәгенә
Татар малаеның
Сыйган бөек Идел,
Сыйган нәни болын...

Таянырга монда
Һәрбер кеше — терәк,
Һәм аларга үзең
Терәк булу кирәк.

Таянсыннар сиңа,
Ә син — дусларыңа.
Батырлыкның башы
Яши әнә шунда.

Яңа ел кунаклары

ҚАТНАШАЛАР:

Шомбай, Су анасы, Шүрәле, Гөлчәчәк, Алып батыр — әкият геройлары.

ҚамАЗ батыр, малайлар, кызлар.

Ш о м б а й:

Исемем минем Шомбай,
Хезмәтем бүген шундый:
Иске елны озату,
Яңасын каршы алу,
Чыршы әйләнәсендә
Бәйрәмне алып бару.
Киткәннәр китә торыр,
Калганнар кала торыр,
Ә бәйрәм бара торыр.
Килеп керер Кыш бабай,
Җырлап, биеп тә йөрер,
Күргәнен сөйләп бирер.
Һөнәр күрсәткәннәргә
Төрле бүләкләр бирер.
Телләрдән җыр агылыр,
Күзләрдән нур чәчелер.
Килгәннәр килә торыр,
Ә бәйрәм бара торыр.

И к е я к т а н и к е к ы з, и к е м а л а й б и е п ч ы г а л а р.

Менә минем дүрт ярдәмчем,
Ике малай, ике кыз.
Бүгенге бәйрәм төнен
Чыкты алар йокысыз.
Йөгерделәр, чаптылар,
Чыршыны бизәштеләр,
Ерак-ерак җирләрдән
Кунакларны дәштеләр.

Кадерле ярдәмчеләрем.
Серегезне ачыгыз?!
Чыршы әйләнәсенә
Кемне дәште
Кайсыгыз?

Беренче кыз:

Су анасын дәшкән идем,
Елганы боз каплаган.
Ахрысы, ул елгасыннан
Чыгар бәке тапмаган.

Беренче малай:

Хәбәр ителгән булса да
Безнең Алып батырга,
Мөмкин бүгенге Алыплар
КамАЗда туктатырга.

Икенче кыз:

Шүрәле килмәкче иде,
Килмәве дә бар аның.
Быел тагын берәр Былтыр
Кыстыргандыр бармагын.

Икенче малай:

Әкияттән чынбарлыкка
Чыгалмыйдыр Гөлчәчәк,
Йомгагы читкә китмәсә,
Вәгъдә бирде — киләчәк.

Беренче кыз:

Әгәр кунаклар килмәсә,
Берсе дә җыйналмаса,
Кыш бабай безгә кермичә
Узып китәр ләбаса.

Барысы бергә:

Чыннан да Кыш бабай безгә
Керми китәр ләбаса!

Ш о м б а й:

Аһ итмәгез, ваһ итмәгез,
Күз яшьләре түкмәгез!
Һәммәсе дә килеп җитәр,
Кунаклар төрле була.
Соңлап килгән,
Көтеп алган
Кунак кадерле була.

Б е р е н ч е м а л а й:

Әй, туктагыз, ни тавыш?
Анда нинди буталыш?!

И к е н ч е к ы з:

Кемдер килә,
Кулына
Олы йомгак тоткан ул.

И к е н ч е м а л а й:

Бу Гөлчәчәк, экияттән
Чынбарлыкка чыккан ул.

Б ә й р ә м ч ә к и е н г ә н б а л а л а р Г ө л ч ә ч ә к н е а л ы п к е р ә л ә р.

Г ө л ч ә ч ә к:

Сезгә килергә чыккач,
Тәгәрәде йомгагым.
Кая гына бармады
Йомгак илткән юлларым.
Эзли-эзли киттем мин,
Күп аралар үттем мин.
Кырдан бардым, куралар
Сызгыргалап торалар.
Ә урманда бүреләр
Улыйлар да улыйлар...
Әллә сезгә киләлмәгән
Кайгыданмы елыйлар,
Улыйлар да улыйлар.

Б а л а л а р:

Аһ, Гөлчәчәк, Гөлчәчәк,
Ничекләр килдең исән?

Г ө л ч ә ч ә к:

Шушы җирдә адашып
Калуым инде дисәм,
Очрады да дусларым
Алып килделәр менә.
Килә икән алар да
Яңа ел бәйрәменә.
Кыскартып юлларымны,
Җыйдылар йомгагымны.

Ш о м б а й:

Мөхтәрәм кунагыбыз,
Рәхим ит, әйдә генә!
Бәхетле балаларның
Бәхетле бәйрәменә.

Ч ы р ш ы   ә й л ә н ә с е н д ә   Г ө л ч ә ч ә к н е   җ и т ә к л ә п   ә й л ә н ә л ә р.

Б е р е н ч е   к ы з:

Күрегез, кем килә безгә,
Ул чәчләре — тезгәчә.
Кулында алтын тарагы
Тирә-якка нур чәчә.

Б ә й р ә м ч ә   к и е н г ә н б а л а л а р   б е л ә н   С у   а н а с ы   к е р ә.

С у   а н а с ы:

Туды көн. Җитте вакыт.
Ә мин бит сезгә киләм.
Тарадым озын чәчемне
Алтын тарагым белән.
Чыкмакчы булсам дөньяга,
Бәкене боз каплаган.

Боз астында әле анда,
Әле монда ташланам.
Мин чабам, кычкырам,
шакыйм!
Барыбер беләм: чыгам.
Ә чабам тарак урлаган
Малайны куган сыман.
Чабам-чабам да җитәм мин,
Ә каршымда боз-тәрәз...
Ни хәл итим боз-тәрәзне
Ватар кодрәт җитмәгәч.
Ни хәл итим, шакыйм, кагам,
Башкаем бәреп, тиле!
Бәкене чабып, дусларым
Чыгарды менә мине...

Икенче малай:

Туктагыз әле, тукта!
Кем ул анда офыкта?

Икенче кыз:

Кемнәр белән, күр әле,
Бу бит безнең Шүрәле.

Шомбай:

Әкиятләр каһарманы,

Балалар:

Рәхим ит!

Шомбай:

Әкиятлеребез даны,

Балалар:

Рәхим ит!

Шүрәле:

Бу яңа елга кергәндә
Тагын шул Былтыр мине
Хур итмәк булган иде дә,
Бетте шул соңгы көне.

Нәни дусларым коткарды,
Дусларым-туганнарым,
Көлдереп алырмын сезне
Авыртса да бармагым...
Көлдерермен дә көләрбез.
Көлдерү изге эшем.
Әгәр минем бармакларга
Юлыкса көлмәс кешең,
Ул көлмичә тора алмас,
Түзә алмас көлмичә —
Яшәргә мөмкинмени соң
Көлү тәмен белмичә.
Тәртипсезләрне дәрестә
Мәңге көлмәслек итәм.
Икеленең ниндилеген
Мәңге белмәслек итәм.

Икенче кыз:

Юк, юк, Шүрәле агай,
Бездә юк андый малай.

Шүрәле:

Булмаса бик шәп, алырмын
Мин сезгә тиеп кенә,
Кети-кети уйныйк әле
Әйләнеп, биеп кенә.

Һәммәсе чыршы тирәсендә әйләнеп биләр.

Икенче малай:

Карагыз, кем килә безгә,
Кем килә, бу бит Алып!

Беренче кыз:

Үзе генә түгел әле,
Килә энесен алып.

Балалар белән бергә Алып, КамАЗ керә.

А л ы п б а т ы р:
Саумысыз, яңа заманның
Булачак Алыплары...
Без — үткән заман, сез — килер
Заманның батырлары.
Ә бүгенге Алып монда
Менә, янымда минем.
Ул минем энем, һәм күптән
Уздырды миннән энем.
Мин селтәнеп җибәргәндә
Сулар айкала иде.
Чабатамны какканда
Артта тау кала иде.
Алып идем мин, бер идем,
Ялгызым гына йөрдем.
Килде бу заман, мин менә
Меңләгән Алып күрдем.
Һәм берсен сезгә бәйрәмгә
Кунакка алып килдем.

К а м А З б а т ы р:

Меңләгән камазчылардан
Сезгә сәлам, дуслар!
Бәйрәмнәр бәйрәме булсын
Безнең бәйрәм, дуслар!
Нинди якты, рәхәт бүген,
Нинди матур утлар.
Никадәр геройлар менә
Әкиятләрдән чыккан.
Бүгенге бәйрәмегездә
Мин дә сездә калам —
Әкият белән чынбарлык
Тигезләшкән заман.

Ш о м б а й:

Телләрдән җыр чәчелер,
Күзләрдән нур агылыр.
Килгәннәр килә торыр,
Ә бәйрәм бара торыр.

Б а л а л а р:

Қыш бабай килә, Қыш бабай!

Һ ә м м ә с е б е р г ә
(такмаклап):
Қыш бабай, Қы-ыш бабай,
Уйнарга,
Җырларга,
Биергә куш, бабай!

Ш о м б а й:

Яндагы ярдәмчеләрем
Баштa куркып калса да,
Қунаклар килде менә,
Бәйрәмебез башлана!

Б ә й р ә м б а ш л а н а.

Без-табигать баласы

Болыт

Бер йомгак кебек булып
Тәгәрәп чыкты болыт.

Башта бик нәни иде,
Җил аны назлап сөйде.

Үчти-үчти иттерде,
Сөя-сөя үстерде.

Менә аякка басты,
Офыкларга тоташты.

Ай үсәсен көн үсте,
Түгә-түгә күз яшен.

...Болыт кына булсаң да
Үсү авыр, күрәсең.

Өй саклаганда

Тәрәзәдән карап торам,
Нигә әле карамаска!
Каравы да ярап тора,
Нигә әле ярамаска!

Ә малайлар уйнап йөри,
Уйный икән уйнасыннар.
Мине Суык бабай тышка
Чыгармый дип уйласыннар.

Янәшәмдә нәни энем,
И сөенә, торып баскан.
Тәпи атламакчы була,
Нигә әле атламаска!

Ә малайлар уйнап йөри,
Уйный икән уйнасыннар!
Мине әти-әни өйдән
Чыгармый дип уйласыннар.

Әти эштә, әни эштә.
Энем тәпи өйрәнүгә
Тау шуарга, кар көрәргә
Чыгачакбыз бергә-бергә.

Ә малайлар уйнап йөри,
Уйный икән уйнасыннар!
Җылы өйдә үзе генә
Утыра дип уйласыннар.

Минем юлым уңачак

Кара мәче, кара мәче,
Юл аркылы йөгермәче!
Минем юлым уңачак,
Менә дигән булачак.
Карлыганмы, җиләкме,
Бөрлегәне кирәкме.
Тырысларым тулачак,
Өем-өем булачак!
Бу бит минем урманым,
Минем болын-кырларым.
Әйт инде менә шуннан:
Мин нинди егет булам,
Белмәсәм урманымны,
Болыным-кырларымны?
Мутланып, кара мәче,
Юл аша йөгермәче!
Барыбер юл уңачак,
Менә дигән булачак!

Кисәтү

Урманың киң, кырларың киң,
Көннәр буе йөгерәсең,
Ә җитмәсә килеп безнең
Алмагачны кимерәсең.

Куян, куян, куянкаем,
Бик кадерле үзең миңа...
Әмма татлы алмаларны
Кем ашатыр көзен миңа?

Кишер дә юк, үлән дә юк,
Аңлыйм синең хәлеңне дә.
Мин үзем дә бик яратам
Баллыны да, тәмлене дә.

Әткәй-әнкәй күрми диеп
Кәнфитләргә сузылуга,
Авырттырып кашык белән
Кулыма — шалт! —
Әби суга.

Куян, куян, куянкаем,
Минем хәлдә кала күрмә.
...Әткәй капкын куеп йөри,
Ялгыш килеп каба күрмә.

Әкият башы

Борын-борын заманда,
Безнең әби-бабайлар
Атынганда таганда;
Җир кирегә әйләнгәндә,
Җәен карлар яуганда,
Кошлар кышын бездә калып,
Язын китеп барганда;
Без коенган елгадагы
Сулар үргә акканда;
Кояш көнбатыштан чыгып
Көнчыгышка батканда
Яшәгән, ди, яшәгән...
Яшәгән, ди, шул менә...
Кем яшәгән? Нишләгән?
Мин башладым,
Син сөйлә!

Керпе, керпе...

Керпе, керпе —
Урман күрке,
Үпкәң бармы әллә миңа,
Нигә инде ачылмыйсың?

Керпе, керпе —
Урман күрке!
Посып кына карап торам,
Ник борыныңны качырмыйсың?

Керпе, керпе —
Урман күрке,
Янә калдың йомгак булып,
Әллә тагын качыйммы соң?

Тәмле шул

И, урманда җиләк,
Җыйсаң чиләк-чиләк.
Сарып йөрим киләп,—
И-и-и, урманда җиләк!

Кай төштә күбрәк,
Кай төштә күбрәк?

Вакыт үтте, җиләк
Очрый сирәк-мирәк.
Сарып йөрим киләп —
Кулымда буш чиләк.

Тәмле шул бигрәк,
Тәмле шул бигрәк.

Ике әтәч

— Сары әтәч, сары әтәч,
Баш түбәндә кикригең.
Ә ул сиңа нигә кирәк,
Ул кикрикне ник киден?

Ни гомерләр шул хикмәтне
Калдырмыйсың бит инде,
Я кикригең яки башың
Очып төшәр беркөнне!

...Килеп чыкты кара әтәч,
Канат какты,
Очынды...
Ул кинәт сары әтәчкә
Очынып кунмасынмы!

Менә ул аның мәһәбәт
Кикригенә үреләә.
Әйтерсең лә инде аңа
Җитмәгән берәү генә.

Алар әзер бер-берсенең
Кикрикләрен алырга,
Мөмкин болар кызулыктан
Күзләрен чыгарырга.

Тирә-якта мамык кына
Очып йөри әйләнеп.
Аңлый алмыйм, болар өчен
Кайда җир дә, кайда күк.

Инде миңа кирәк түгел
Сары әтәч кикриге.
Ике малай — ике әтәч
Татулашсыннар иде.

Күл өстендә алкалар

Күзге кебек күл өсте,
Таш аттым,
килеп төште.
Матур-матур алкалар
Тәгәрәшеп яталар.
Урталыктан качалар,
Карап торам аларга:
Хәлләре бетеп, барып
Егылдылар ярларга.

Бака туе

Суга төшеп җитә алмыйм,
Күл буендагы бака
Шар ярып бөтен дөньяга
Кычкыра: «Ба-та! Ба-та!»

Ә үзе, мин гайрәтләнеп
Ярга килеп басуга,
Куркуыннан камыш үскән
Сазлыкка кереп чума.

Нәкъ шуны гына көткәндәй
Башлана бака туе:
— Ба-та-ба-та-та! —диеп алар
Кычкыра төне буе.

Сораулы караш

— Аем, аем, бу синме соң,
Нигә көндез күренмисең?
— Кешем, кешем, сезнең өчен
Минем көндез кояшым бар.

— Кояш, кояш, бу синме соң,
Нигә төнлә күренмисең?
— Сезгә якты булсын өчен
Айга нурлар коясым бар.

—Болыт, болыт, бу синме соң,
Көн димисең, төн димисең?
— Сезгә иген үссен өчен
Җир сугарып куясым бар.

...Сорауны да бирәм үзем,
Үзем бирәм җавапны да.
Күкләр миңа
Минем кебек
Сорау белән карап тора.

Гариф диган бер малай...

Космонавтлар Галәмне
Урап кайтып төшсә дә,
Гариф өчен һәммәсе
Бик тә җиңел мәсьәлә.
— Утырып китәсең,— ди ул,—
Барып җитәсең,—ди ул.—
Менгәч инде нишләрсең —
Герой булып төшәсең.
Абыйлары Чаллыда
«КамАЗ»лар төзесә дә,
Гариф өчен һәммәсе
Бик тә җиңел мәсьәлә.
— Чыгып китәсең,— ди ул,—
Барып җитәсең,— ди ул,—
Кранга утырасың,
Колакларын борасың.
Боргач инде колагын,
Йөрми хәле юк аның.
Күтәрә дә сала,— ди,—
«КамАЗ» китеп бара,— ди.
Укытучы апасы
Өйгә биргән мәсьәлә.
Никадәр утырса да,
Чыкмый әллә нәрсәгә.
Кинәт төшә исенә,
Җайлы юлы бар аның.
Китап артын актарып,
Эзләп карый җавабын.
Дәшә энекәшенә:
— Гаепләмә без әле!
Язмаганнар җавабын,—
Чишә алмый үзләре!

Көлә аннан энесе:
Җавап язу нәрсәгә,
Ул бит сеңелем чишәрлек
Бик тә гади мәсьәлә!

Көзге аваз

Уч төбедәй нәни яфрак
Килеп кунды уч төбенә.
Канат кагып әллә кая
Очар сыман и җилпенә.

Бер агачтан сикерде дә
Уч төбенә кунды бары.
Уч төбен кытыклап алды
Алтын-сары томшыклары.

Кыр казлары тезмәсенә
Иярмәкче булды мәллә?..
...Көзге аваз — кош авазы
Дәшә бугай киңлекләргә.

Кабак

Яз көне бу түтәл
Яфракка төренде.
Җитте көз, тау кадәр
Кабагы күренде.

Ята ул сөенеп,
Күкрәген киереп,
Һәркемгә әйтә күк:
— Менә мин кем! — диеп.

Ә аны алдылар,
Урталай ярдылар.
Төшләрен чистартып,
Бәлешкә салдылар.

Камырга киенеп,
Күкрәген киереп
Утыра өстәлдә:
— Менә мин кем! — диеп.

Ак майны сөрттеләр,
Кисәкләп кистеләр.
Сәгать тә үтмәде —
Төбенә төштеләр.

Туклыкка тиенеп,
Күкрәкне киереп
Утыра кешеләр:
— Без менә кем! — диеп.

Ямь-яшел

Күктә йөзгән ак болытлар
Ямь-яшел.
Ал нурлар япкан офыклар
Ямь-яшел.
Бормалы авыл юллары
Ямь-яшел.
Сары арыш басулары
Ямь-яшел.
Ә агачлар...
Менә яшел, ичмаса.
Карау кызык...
Яшел пыяла аша.

ЭЧТӘЛЕК

Безнең матур дөньябыз

Без 5
Безнең авыл 6
Без хәзер зур көч булдык 7
Бәйрәм бүген бездә 8
Саубуллашу 8
Безнең «диңгез» 9
Безнең язу 10
Урамыбыз тузаны 11
Клубта 12
Җир-ана, кояш һәм кешеләр (баллада) 13

Матурлык безнең белән...

Матурлык минем белән 19
Көзем — җанлы табигатем 19
Яшәү 20
Яфрак җыры 21
Йорт казлары 22
Инешнең илгә кайтуы 22
Кечкенә легенда 23
Арча кыры 24
Билгесез солдат 25
Батырлыкның башы 26
Соңгы сүз 27
Ышаныч 28
Оран 28
Яңа ел уты 30
Яңа ел кунаклары 31

Без — табигать баласы

Болыт 41
Өй саклаганда 42
Минем юлым уңачак 43
Кисәтү 44
Әкият башы 45
Керпе, керпе... 46

Тәмле шул 47
Ике әтәч 48
Күл өстендә алкалар 49
Бака туе 49
Сораулы караш 50
Гариф дигән бер малай... 51
Көзге аваз 52
Кабак 53
Ямь-яшел 54

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА

Аглямутдинов Мударрис Зуфарович

МЫ — ЭТО МЫ

СТИХИ

(на татарском языке)

Рецензенты **Р. А. Фәйзуллин.** Редакторы **Р. Т. Вәлиева.** Техник редакторы **Ф. Х. Абдрахманова.** Художество редакторы **Р. Г. Шәмсетдинов.** Корректоры **М. М. Мирсалихова.**

ИБ № 1906

Наборга бирелде 27/V-1980 ел. Басарга кул куелды 22/VII-1980 ел. Формат $60\times90^1/_{16}$. 100 гр. офсет кәгазе. Гарнитура литературная. Печать высокая. Учет. изд. табагы 1,9. Басма табагы 3,5. Заказ У-244. Тираж 8000. Бәясе 20 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

20 тиен.